# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы дәүләт милкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт милкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьядагы 2 өлешнең 2 пунктында «буенча» сүзеннән соң «, шул исәптән әлеге Законның $12^1$ статьясындагы нигезләмәләрне гамәлгә ашырганда,» сүзләрен өстәргә;

2) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. **Дәүләт милкәтен түләүсез файдалануга тапшыру**

1. Дәүләт милкәте Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, юридик һәм физик затларга сәламәтлек саклауны, мәгарифне, халыкка социаль хезмәт күрсәтүне, физик культураны һәм спортны, мәдәниятне үстерүгә; мәдәни кыйммәтләрне, гражданнар оборонасы, торак-коммуналь хуҗалык объектларын саклауга; юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә; Татарстан Республикасы торак фонды, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына, терлек каберлекләренә, гидротехник корылмаларга хезмәт күрсәтүгә бәйле максатларга,

әгәр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында дәүләт мөлкәте белән мондый алым ярдәмендә һәм әлеге статьяда күрсәтелгән максатларда эш итүне тыя торган нигезләмәләр булмаса, түләүсез файдалануга тапшырылырга мөмкин.»;

3) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. **Дәүләт мөлкәтен арендага бирү**

1. Дәүләт мөлкәтен арендага бирүчеләр түбәндәгеләр:

1) законнарда билгеләнгән очракларда үз вәкаләтләре чикләрендә казна мөлкәтенә һәм башка мөлкәткә карата башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы;

2) үзләренә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән мөлкәткә карата Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре;

3) үзләренә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәткә карата Татарстан Республикасы казна предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре;

4) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә дәүләт мөлкәтен арендага бирү хокукына ия затлар.

2. Аренда түләвен билгеләү һәм исәпләү методикасы һәм ысуллары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ статья өстәргә:

«$12^1$ статья. **Дәүләт мөлкәтен бүләк итү**

Дәүләт мөлкәтен бүләк итү законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырылырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 75-ТРЗ